


Мордовия мәктәпләрен тә- мамлаучыларнын барысы да аттестатлар алды инде. 9нчы сыйныф укучылары очен бу уку елы тәмамланды, алар очен имтиханнар (ОГЭ) быел гамәлдән чыгарылды. Югары уку йортларына керергә жыенмаган унберенче сыйныф укучыларына да ЕГЭ (БДИ - бердәм дәvләт имтиханы) тапшырырга кирәкми. Аттестатка билгеләр бер ел эчендә йомгаклау бәяләре нигезендә куелган, - дигән мәгълумат белән Мордовия Правительствосы Председа- теле заместителе, Дәvләт заменацион комиссия председателе Галина Алексеевна Лотванова пресс-конференциядә уртаклашты. Шулай ук бу конференциядә Мордовия мәгариф министры Галина Анатольевна Явкина Мордовиядә торле уку предметлары буенча ЕГЭ vткәрv тәртибе турында корреспондентларга сойләде һәм сорауларга жавапларны ишеттерде.      - Быел Мордовия мәктәпләрендә 3305 унберенче сыйныф укучысы. Аларнын бары унбере генә ЕГЭ тапшырырга жыенмый, ягъни вузга укырга керергә планлаштырмый. ЕГЭда катнашырга теләп  барлыгы 3294 гариза бирелде. Техникум һәм коллиятләрне тәмамлаган 62 укучы ЕГЭ тапшырачак – алар югары белем алырга ниятли. Остәвенә, 148 кеше - узган елларда мәктәпне тәмамлаучылар арасыннан. КИМнар vткән елдангыларыннан аерылмый - идентичны; алдагы еллардагы технологияләр буенча vт- кәреләчәк.

Мордовиядә ЕГЭ vткәрv буенча 22 пункт һәм ойдә тагын 9 пункт эшләячәк. Имтиханнарны vткәрvнен топ вакыты  - 3 июльдән 25 июльгә кадәр. Остәмә   - 3 августтан 8 августка кадәр. Август коннәрендә имтиханнарны нигезле сәбәпләр аркасында документальраслаулары булган кешеләр тапшыра ала. Мәсәлән, авыру буенча. Яки әгәр сайланган предметлар бер конгә туры килә. Ә менә быел ЕГЭны янадан тапшыру рохсәт ителми. Әгәр укучы минималь балл жыймаса, ул янадан имтиханга киләсе елда гына килә алачак, - ди Галина Алексеевна пресс-конференциядә.

Унберенче сыйныф укучыларынын беренче ЕГЭлары 3 июльдә узачак - бу конне алар география, әдәбият һәм информатиканы тапшырачак, әмма олкәннәр очен имтиханнар иртәрәк башланачак. Инде 23 июнь - беренче тренировка коне, анын барышында информатика буенча имтихан vткәрv технологиясе эшләнә. Барлык 22 пункт ачылыр. Тренировка имтиханында оештыручылар, ГЭК әгъзалары, пункт житәкчеләре, мәктәп директорлары катнаша. Мондый тренировкалар гадәттә яз башын уза, әмма быел аларны vткәрv момкин тvгел иде, дип тә ишеттерделәр чыгыш ясаучылар.

ЕГЭ vткәрv пунктларында жәмәгать кvзәтvчеләре гадәттәгедән азрак булачак – бер пунктта 2 кеше. Әмма онлайн-кvзәтvчеләрнен кин даирәсе жәлеп ителәчәк, аларнын

эшен видеокvзәтv белән тәэмин итәчәкләр. Тобәк мәгълvмат Үзәгендә имтихан барышын 45 кеше кvзәтеп торачак; аларнын 35е турыдан-туры Үзәктә урнашачак, 10 оператор дистанцион режимда эшләячәк.
- Әйтеп китәргә кирәк, быел унберенче сыйныф укучыларын котә торган имтиханнарда санитар нормаларны vтәvгә аерым игътибар бирелә. Нәкъ менә шуна кvрә рус теле буенча ин кvп бала тапшыра торган имтиханны ике кон: 6 һәм 7 июльдә vткәрv турында Карар кабул ителде, дип ишеттерде мәгариф министры. - Югыйсә чыгарылыш сыйныф укучыларын аудиторияләргә урнаштыру буенча тәкъдимнәрнен vтәлешен тәэмин итv момкин тvгел. Таләпләрнен берсе - 1,5 метрдан да ким булмаган кvләмдә социаль дистанцияне vтәv.
Башта бер конгә куелган химия һәм җәмгыять белеме (обществознание) буенча имтиханнар Мордовиядә аерым узачак, чонки аларны бик кvп чыгарылыш сыйныф укучылары сайлаган. Җәмгыять белеме буенча ЕГЭ -16 июльдә, ә химия буенча - 24 июльдә vтәчәк.
Барлык оештыручылар имтиханда шәхси саклану чаралары белән тәэмин ителәчәк: битлекләр, перчаткалар, дезинфекция чаралары сатып алынган. Имтихан тапшыру очен җәлеп ителгән 294 аудиториянен һәркайсында һаваны зарарсызландыручы рециркуляторлар урнаштырылачак. Имтиханга кадәр һәм аннан сон барлык коридорлар, рекреация, бәдрәф бvлмәләре дезинфекция чаралары белән эшкәртеләчәк. Бинага кергәндә барысына да кулларны эшкәртv vткәреләчәк. Әмма укучыларга битлек һәм перчаткалар кию кирәкми.
Әйтеп китәргә кирәк, Ботенроссия «Чыгарылыш кичәсе» онлайн 27 июньдә узачак. Мәгариф министрлыгы мәктәпне тәмамлаучыларга багышланган бәйрәм чараларын 27 июнь конне билгеләде. Мондый чаралар арасында - ботен тобәкләрне vз эченә алган гомумфедераль «Чыгарылыш кичәсе», анын программасы ел саен vткәрелә торган «Ал җилкән» фестивале дә булачак.

**Наилә НАСЫРОВА**